
И туган тел, и матур тел...

# Асылташ




**Хатын-кызның язмышы ил, милләт язмышыннан аерылгысыз. Ул – күп рольләрне үзендә берләштерә алган шәхес. Юкка гына туган тел турында сөйләшкәндә дә «ана теле» дип әйтмибез бит, телне балага бирүче кеше дә – хатын-кыз. Милләтебезнең хәзерге асыл затлары – кемнәр, бүгенге заман туташ-ханымнары нинди? Яңа сәхифәбездә әнә шул сорауга җавап табарга тырышачакбыз.**

## Руфина Фәттахова – табибә, әни

ӘҢГӘМӘНЕҢ ВИДЕО ВАРИАНТЫ



Зөләйха Камалова

**МӘХӘББӘТСЕЗ БУЛМЫЙ!** Кемне дә булса бүтәннәрдән аерып яратасың инде ул. **ДУСЛЫК, ХӨРМӘТ МӘХӘББӘТКӘ КҮЧӘ АЛА.**

**БЕЗ – ИЛДӘГЕ ШАКТЫЙ ҮЗГӘРЕШЛӘРНЕ КИЧЕРГӘН БУЫН.** Икетеллелек юк заманнар булды. Әйтик, чиратта, трамвайларда татарча сөйләшеп кара син! Берзаман шундый очрак булды. «Почему ты с ребенком разговариваешь на своем языке?» – диде миңа бер хатын. Мин дә, аптырап: «Как? Это же мой ребенок!» – дим. Ул исә: «Дәүләт теле – рус теле, шулай булгач, русча сөйләш!» – димәсенме?! Шул вакытта мине трамвайдагыларның берсе дә якламады. Әйе, шундый чорлар да бар иде...

Кем сиңа хәзер өеңдә татарча сөйләшергә кирәк бирми? Нигә балаңа татарча китап укымыйсың? Кызыклы, матур рәсемле, эчтәлекле китаплар бик күп бит! Нигә телне өйрәтмисең? Безнең халык моны аңлардлык дәрәҗәгә һаман да җитмәде. **БЕЗ ҺАМАН ЗАР ЕЛЫЙБЫЗ.**

Хәзер кайбер татар авылларында да балалар татарча сөйләшми диярлек. Шәһәр балаларын, телне өйрәнсен дип, авылга алып кайтасың, ә анда... Әби-бабайлар да оныклар белән **ВАТА-ҖИМЕРӘ РУСЧА СӨЙЛӘШЕРГӘ ТЫРЫША.** Читтән карап торганда бу хәтта көлке дә! Рәхәтләнеп үз оныгың белән үз телеңдә сөйләш бит!

**БАЛАНЫҢ ТЕЛЕ ТАТАРЧА АЧЫЛЫРГА ТИЕШ.** Бала тугач та, хатын-кыз өйдә утыра бит әле. Менә бу чорда рәхәтләнеп татарча сөйләш аның белән, татарча укы. Рус телен белмәгән бала юк ул. Балага исем сайлауга да җаваплы карарга кирәк.

**ХӘЗЕР ХАЛЫК КИТАПНЫ АЗ УКЫЙ.** Телевизор, интернет барлыкка килү белән барысы да үзгәрде. Элек бүләккә дә китап бирә идек бит, бик күп укый идек чөнки.

Хатын-кызның эше күп дигәндә, елмаясы килә. Бу бит хатын-кызның кайда яшәвенә дә карый. Бүгенге хатын-кызның вазыйфалары без үскәндәге вазыйфалардан аерыла. **БЕЗ ҮСКӘН ЧОРДА ХАТЫН-КЫЗ УЛ – АШАРГА ПЕШЕРҮЧЕ ДӘ, КЕР, ИДӘН ЮУЧЫ ДА, ИР ХАТЫНЫ ДА, ТАГЫН ӘЛЛӘ КЕМ ДӘ...** Мәсәлән, мин кер элергә яратам, чөнки аны хәзер машина юа. Ирем (Нурихан Фәттах – язучы. – **Авт.**) элек: «Шимбә, ял көннәрендә синең арт ягыңны гына күреп була!» – дип әйтә торган иде.

**ХАТЫН-КЫЗ ХАТЫН-КЫЗ БУЛЫП КАЛЫРГА ТИЕШ.** Кияүгә чыктым, бала таптым, хәзер үзем турында онытсам да ярый, диясе түгел! «Әй, өйдә халат кисәм дә ярый, чәчемне карамасам да була, ирем мине барыбер ярата бит!» – дип кул селтәү килешми инде. Хатын-кызны нәфис зат диләр икән, бу нәфислек калырга тиеш.

Мин тупас хатын-кызны яратмыйм. Гаиләдәме, җәмгыятьтәме – балаларына, иренә кычкырганны, сукканны җенем сөйми. Кеше сүзендә тормый икән, андыйларны шулай ук хөрмәт итәсе килми. **ҮЗЕҢ НИНДИ, КЕШЕДӘН ШУНЫ ТАЛӘП ИТӘСЕҢ, ГАДӘТТӘ.**

Балалар үстердем. Алар – беренче буын. Оныклар – икенче буын. Аларның балалары исә бөтенләй безгә охшамаган. **ОНЫКЛАР ҮЗЛӘРЕНЕҢ БАЛАЛАРЫНА КАРАТА БИК ИГЪТИБАРЛЫ.** Мин балаларны болай итеп тәрбияли алмадым да кебек... Эш, эш, эш иде.

**МИҢА ИҢ ОШАМАГАНЫ** – кем генә, нинди генә милләт вәкиле булуына карамастан, **ГҮЗӘЛ ЗАТНЫҢ ХАТЫН-КЫЗЛЫГЫН ЮГАЛТУЫ.** Үзеңне хатын-кыз итеп хис итү өчен матур итеп киенү генә җитми.

**ҮЗЕҢНЕ ХАТЫН-КЫЗ ИТЕП САКЛАР ӨЧЕН, КӨЧ, ТЫРЫШЛЫК КИРӘК.**

Мин – укытучы кызы. Ә укытучылар өйдә дә укытучы булып кала. **БЕЗНЕ КЕШЕНЕ ХӨРМӘТ ИТӘРГӘ ӨЙРӘТТЕЛӘР.**

Нурихан Фәттахның хатыны дип тә, табибә буларак та бер чама беләләр мине. Нурихан мине **ЧИКЛӘМӘДЕ.** «Юк, йөрмисең, эшләмисең, болай итмисең», – димәде.

**ХАТЫН-КЫЗ ҮЗЕН ЯРАТЫРГА ТИЕШ!** Ә нигә юк? Әгәр ул үзен яратмый икән, башкалар да яратмаячак.

Бар ул «эчке матурлык» дигәннәре. **БУ КИТАП СҮЗЕ ГЕНӘ ТҮГЕЛ ИКӘН!** Моңа яши-яши төшенәсең.

Хатын-кыз тыштан бик матур булырга мөмкин. **ӘММА УЛ КОРЫ, ТӨРТМӘ ТЕЛЛЕ ИКӘН, АНЫҢ ТЫШКЫ МАТУРЛЫГЫ КҮРЕНМИ БАШЛЫЙ.** Кешеләр синең ярдәмчеллегеңә, кешелекле якларыңа игътибар итә.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде. Видео: Лилия ГЫЙМАЗОВА